РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ИЗМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422052, Республика Татарстан, Сабинский район,
с.Измя, ул. Школьная, 9
тел. (84362) 49-1-32, (84362) 49-1-22

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЭЗМӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422052, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Эзмә авылы, Мәктәп урамы, 9 йорт
тел. (84362) 49-1-32, (84362) 49-1-22

e-mail: Izm.sab@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　　　КАРАР

24.04.2019　　　　　　　　　　№ 33

Сабамуниципаль районы Эзмә
авыл җирлеге җирле үзидарә органнары
тарафыннан күрсәтелүче муниципаль
хезмәтләр исемлеген раслау турында

" Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны тормышка ашыру максатында, Татарстан республикасы Саба муниципаль районы Эзмә авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Эзмә авыл җирлеге җирле үзидарә органнарытарафыннан күрсәтелүче муниципаль хезмәтләр исемлеген расларга.

2. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Эзмә авыл җирлеге башкарма комитетының 14.07.2011 елгы №19 "Җирле үзидарә органнарытарафыннан күрсәтелүче муниципаль хезмәтләр исемлеген раслау турында" карарын үз көчен югалтkan дип танырга.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Саба муниципаль районы Эзмә авыл җирлегенең рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://saby.tatarstan.ru/rus/izma җирлекнең информацион стендларында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Эзмә авыл җирлеге башлыгы:　　　　　　А.Р.Шайхетдинов

Эзмә авыл җирлеге
башкарма комитетының
24.04.2019 елгы №33
карары белән РАСЛАНГАН

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Эзмә авыл җирлеге җирле үзидарә органнары тарафыннан күрсәтелүче дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр исемлеге

| | |
|---|---|
| 1 | Адреслар бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару |
| 2 | Документларның күчермәләрен һәм алардан өземтәләрнең дөреслеген раслау |
| 3 | Нотариаль гамәлләр кылу: васыятьнамә яки ышанычнамәләрне раслау |
| 4 | Белешмәләр (өземтәләр) бирү |
| 5 | Агачлар яки куаклыкларны кисәргә, төпләргә яки утыртырга рөхсәт бирү |
| 6 | Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирүгә мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу |
| 7 | Муниципаль торак фондыннан гражданга социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны бирү |
| 8 | Муниципаль торак фондындагыторак урыннарынгражданнарга хезмәт торак урынын найм шартнамәләре буенча бирү |
| 9 | Төзелеп беткән территорияләрне үстерү өчен җир кишәрлекләре бирү |
| 10 | Торак төзелеше максатларында аны комплексны үзләштерү өчен муниципаль милектә булган җирләрдән җир кишәрлеген арендалау шартнамәләрен төзү хокукын сату буенча торглар оештыру һәм үткәрү |
| 11 | Күчемсез милек объектларына муниципаль милек реестрыннан өземтә бирү |
| 12 | Җирлектәге муниципаль милектәге биналарны, корылмаларны һәм торак булмаган биналарны арендага бирү |